Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы муниципаль
бюджет гомуми урта белем учреждениесе
“Имәнкискә урта гомуми белем мәктәбе”

# “ӨЧ ХАЛЫК – ӨЧ МИРАС”

## дәрестән тыш эшчәнлек проекты

*Эшне башкарды:*



*Шәймөхәммәтова Алия*
*Мөхәммәтҗан кызы,*
*югары квалификацион категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты*
*укытучысы*

*Иманкиска - 2022*

**ЭЧТӘЛЕК**


| | | |
|---|---|---|
| 1 | КЕРЕШ | 3 |
| 1.1 | ПРОЕКТНЫҢ ПАСПОРТЫ | 4 |
| 1.2 | ПРОЕКТНЫ ГАМӘЛГӘ КЕРТҮ ПЛАНЫ | 6 |
| 1.3 | РЕСУРСЛАР | 7 |
| 1.4 | ПРОЕКТНЫҢ НӘТИҖӘСЕН, УКУЧЫЛАРНЫҢ РУХИ-ӘХЛАКЫЙ ТӘРБИЯСЕН БӘЯЛӘҮ ҺӘМ ТИКШЕРҮ МЕТОДИКАСЫ | 8 |
| 2 | ТӨП ӨЛЕШ | 9 |
| 2.1 | ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК ПРОГРАММАСЫ | 9 |
| 2.1.1 | АҢЛАТМА ЯЗУЫ | 9 |
| 2.1.2 | ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК ПРОГРАММАСЫ ЭЧТӘЛЕГЕ | 12 |
| 2.1.3 | КАЛЕНДАРЬ-ТЕМАТИК ПЛАН | 13 |
| 2.2. | “ӨЧ ХАЛЫК - ӨЧ МИРАС” ПРОЕКТЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУДА МӘКТӘП МУЗЕЕНЫҢ РОЛЕ. | 16 |
| 3 | ЙОМГАКЛАУ | 17 |
| 4 | КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ | 18 |
| 5 | КУШЫМТА. ФОТОМАТЕРИАЛ | 19 |

# 1. КЕРЕШ

Рухи һәм әхлак тәрбия проблемасы бүгенге көндә безнең җәмгыятебездә бик кискен тора. Моңа сәбәпләр бик күп. Укучыларда рухи, милли һәм әхлак тәрбиясе бирүдә, аларны халкыбызга хезмәт итәрдәй шәхес буларак формалаштыруда әдәбият укытучыларының роле зур. Яшь буынга милли яшәү рәвешен җиткерүдә, аның үзаңын үстерүдә, бу юнәлештә гамәли адымнар ясауга әзерләүдә әдәбият мөһим җирлек булып тора. Әдәбият дәресләренең нәтиҗәлелеген арттыруда дәрестән тыш эшчәнлек нык ярдәм итә. Шул форсаттан төзелгән “Өч халык - өч мирас” дип аталган дәрестән тыш эшчәнлек проекты, яшәгән төбәгебездә – Чырпы авылы җирлегендә, дус-тату яшәүче рус, керәшен, татар халыклары мәдәнияте аша укучыларга рухи һәм әхлак тәрбиясе бирүне куздә тота. Билгеле, кайсы төбәктә яшәвенә карамастан, һәр укучы үзе яши торган төбәкнең табигатен, аның үзенчәлекләрен, халкын, традицияләрен, мәдәниятен, тарихын аеруча яхшы белергә тиеш. Әхлак тәрбиясе бирү хәзерге көндә һәр педагогның төп бурычы. Аны һәркем үзенчә чишә. Бүгенге заман укучысы, үскәч, нинди булыр икән, кеше хәленә керә, кайгыра белү, якын кешесенә ярдәм кулы сузу кебек хисләргә сәләтле булырмы, карадан акны аера белерме?

**Проектның актуальлеге.** Яңа Федераль дәүләт белем бирү стандартлары төп ориентир буларак, урта мәктәпне тәмамлаучының шәхес буларак һәрьяклап формалашуын күздә тота. Уку процессында формалаштырырга, үстерергә һәм камилләштерергә кирәк булган характеристикалар бүген төгәл билгеле. Шул исәптән, чыгарылыш сыйныф укучысына шәхси нәтиҗәләргә ирешү өчен башка мәдәният вәкилләре белән бергә яши, аралаша белү һәм уртак эшчәнлек нәтиҗәсенә ирешү таләпләре дә куела. Моның өчен чит халыкларның гореф-гадәтләренә һәм мәдәни мирасына хөрмәт белән карарга, һәр халыкның милли үзенчәлекләренә толерант булырга кирәк. Шулай итеп, федераль дәүләт белем бирү стандартлары поликультур дөньяда яшәгән хәзерге заман кешесенең дөньяга карашын формалаштыру өчен илебездә, туган ягыбызда яшәче халыклар мәдәниятен өйрәнүне ассызыклый.

Без яши торган Лаеш муниципаль районы Чырпы авылы җирлеге өч авылны - өч халыкны - өч мирасны берләштерә. Бик күп еллар Чырпы авылында руслар, Мирәтәк авылында керәшен татарлары, ә Имәнкискә авылында татарлар гомер итә. Һәр халык үзенең гореф-гадәтләре, йолалары, дине белән үзенчәлекле. Бәйрәмнәр, җыелышлар, җыеннар, күмәк эшләр, күнелле һәм кайгылы да вакыйгалар өч авыл халкы өчен уртак.

Безнең, укытучыларның бурычы - бу мөхиткә җайлашып яши белүче, иъгтибарлы, ихтирамлы, шул ук вакытта абруйлы да булган толерант шәхесләр тәрбияләү.

## 1.1 ПРОЕКТНЫҢ ПАСПОРТЫ

**Проектның максаты:** "Укучыларга милли төбәк компоненты аша рухи һәм әхлак тәрбиясе бирү эшчәнлеге программасын төзү һәм аны дәрестән тыш эшчәнлектә сынап карау."

**Проектның бурычлары:**

1. Федераль дәүләт белем стандартлары буенча укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру таләпләрен өйрәнү;

2. Татар, рус, керәшен халыклары мәдәнияте аша укучыларда кешелек сыйфатлары, намуслылык, ата- анага, олыларга карата хөрмәт тәрбияләү;

3. Имәнкискә авылында яшәп, җирле халык белән аралашкан укучыларны шул халыкларның әдәби-мәдәни байлыгы белән якыннан таныштыру;

4. Халык авыз иҗаты турында тулы күзаллау булдыру, аны баланың үз туган халкының рухи җәүһәрләре белән чагыштырырга күнектерү;

5. Укучыларда фәнни эзләнү–тикшеренү күнекмәләре формалаштыру;

6. Төрле мәдәниятен, көнкүрешен иҗади яктан өйрәнү һәм аңлый белү;

7. Тәнкыйди, креатив фикерләү аша укучыларның иҗади сәләтен ачу һәм аңын үстерү.

8. Чырпы авыл Советы гамәлгә куючы "Имәнкискә-Татарстанның йөзек кашы", "Өч халык- өч мәдәният" проектларына кушылып китү

9. Музей өчен экскурсоводлар әзерләү

**Тикшерү объекты:** Укучы шәхесендә рухи һәм әхлак сыйфатларының үсеше

**Тикшерү предметы:** класстан тыш эшчәнлек аша укучыларны рухи һәм әхлак ягынан тәрбияләү.

**Гипотеза:** Уку процессында милли-төбәк компонентын куллану яшьүсмерләрнең рухи-әхлакый сыйфатларын формалаштыру һәм үстерүне тагын да уңышлырак итә

**Проектның практик әһәмияте һәм яңалыгы:** укытучыларга кулланма өчен материал була алуында.

**Проектны тормышка ашыру вакыты:** 2021 нче елның 1 нче августыннан 2022 нче елның 31 нче маена кадәр.

**Проектны тормышка ашыру урыны:** Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы “Имәнкискә урта гомуми белем бирү мәктәбе” (алга таба МБОУ “ИСОШ”)

**Проектның максатчан группасы:** 7 нче сыйныф укучылары.

**Проектны тормышка ашыру этаплары:**

1. Әзерлек этабы. 2021 нче елның август ае

ФДБС өйрәнү, анализлау, дәрестән тыш эшчәнлек планын төзү.

2. Төп этап. 2021 нче елның 1 нче сентябреннән 2022 нче елның 31 нче маена кадәр

Проектның эчтәлеген гамәлгә кертү.

3. Йомгаклау этабы. 2022 нче елның июне

Нәтиҗә ясау, йомгаклау, нәтиҗәлелекне ачыклау һәм киләсе уку елына төзәтмәләр кертү. Яңа максат һәм бурычлар билгеләү.

**Проектны гамәлгә кертүнең каршылыклары**

1. Әти-әниләрнең хезмәттәшлек итәсе килмәве
2. Укучыларның дәрестән тыш эшчәнлектә катнашырга теләмәүләре, милли төбәк компоненты белән кызыксынмаулары
3. Мәгълүмати чараларның тиешле дәрәҗәдә төзек, я кулланышта булмавы.
4. Техник чараларның ватылуы
5. Мәктәп администрациясенең проект кыйммәтен аңлап җиткермәве.

**Проектны гамәлгә кертүнең көтелгән нәтиҗәләре**

Милли төбәк компоненты – күпмилләтле җөмһүриятебездә халыклар дуслыгын ныгытуда мөһим ресурс. Ул халыкларның мәдәни һәм тарихи хәзинәсе белән танышу, бер-береңне яхшы белү өчен генә түгел, ә бәлки халыклар арасында тыгыз бәйләнеш барлыгын да күрсәтеп торучы бер дәлил булып тора. Татарстан халыкларының үзара дус, тату яшәве – бөтендөнья өчен толерантлык үрнәге булып торуын да күрсәтә. Халыклар арасында дуслык бәйләнешләрен ныгытуда бәйрәмнәрнең роле зур, чөнки алар аша халыклар бер-берсенең мәдәниятен, яшәү рәвешен, гореф-гадәте, йолаларын өйрәнә һәм шулар аша бер-берсенә хөрмәт тәрбияли, үз итә, дуслыгын ныгыта. Бүгенге көндә милли бәйрәмнәребезне, йола, гореф-гадәтләребез республикабызда яңадан торгызылып,

яңартылып, заман төсмерләре биреп үткәрелә башлады. Аларны халык белә, хөрмәт итә икән- милләт яши, милләт яшәгәч, тел яши, ягъни тормыш дәвам итә.

Проектның ахырында укучыларның белем һәм күнекмәләренә таләпләр (көтелгән нәтиҗәләр) :

- Чырпы авыл советы җирлегендә яшәүче халыкларның йола фольклорын башка халык авыз иҗаты әсәрләреннән аера белү;

– Татар, рус, керәшен халыклары мәдәниятенә, көнкүрешенә игътибарлы һәм ихтирамлы булу;

– Җирлегебездә яшәүче халыкларны тану, аера белү;

- Бердәмлектә көч икәнен ассызыклый белү;

– Туган ягыбыз, аның тарихына, мәдәниятенә карата патриотлык, горурлык хисе, бер-береңә карата ихтирам хисе тәрбияләү;

– Дәрестән тыш эшчәнлектә өйрәнгән теманы, үзләштергән белемне гамәлдә куллана белү;

- Мәктәп музеенда экскурсовод булу;
- Чырпы авыл Советы гамәлгә куючы “Имәнкискә-Татарстанның йөзек кашы”, “Өч халык- өч мәдәният” проектларына кушылып китү

## 1.2 ПРОЕКТНЫ ГАМӘЛГӘ КЕРТҮ ПЛАНЫ

| Чараларның исеме | Үткәрү урыны | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| Россия Федерациясе мәгариф һәм фән министрлыгының 1897 нче боерыгы белән расланган төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандартын (17.12.2010ел) өйрәнү. | МБОУ “ИСОШ” | август | укытучы |
| Татар теле укытучыларының МБ утырышы | МБОУ “ИСОШ” | август | МБ җитәкчесе, укытучы |
| Педагогик киңәшмә утырышы | МБОУ “ИСОШ” | август | администрация |
| 7 нче сыйныф укучыларның ата-аналар җыелышы | МБОУ “ИСОШ” | август | Класс җитәкчесе, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | укытучы |
| Дәрестән тыш эшчәнлек | Татар теле кабинеты | атнага бер тапкыр | укытучы |
| Татар теле укытучыларының МБ утырышы | МБОУ “ИСОШ” | май | МБ җитәкчесе, укытучы |

## 1.3. РЕСУРСЛАР

| **Шартлар** | **кирәк** | **бар** | **чыганак** | **вакыты** |
|---|---|---|---|---|
| **Норматив-хокукый шартлар** | | | | |
| “Мәгариф турында” Россия Федерациясе Законы | | + | | Ел дәвамында |
| “Мәгариф турындагы” Татарстан Республикасы Законы (6, 7, 10, 32 нче маддәләре) | | + | | Ел дәвамында |
| Россия Федерациясе мәгариф һәм фән министрлыгының 1897 нче боерыгы белән расланган төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандарты | | + | | Ел дәвамында |
| 5-9 нчы сыйныфлар өчен мәктәпнең төп белем бирү программасы | | + | | Ел дәвамында |
| Мәктәпнең эш программасы турындагы локаль акты | | + | | Ел дәвамында |
| **Материаль- техник шартлар** | | | | |
| Компьютер | | + | | Дәрес саен |
| Принтер | | + | | Дәрес саен |
| Бастыру өчен кәгазь | | + | | Дәрес саен |
| Флешка | | + | | Дәрес саен |
| Диск | | + | | Дәрес саен |
| Брошюратор | | + | | октябрь |
| Ламинатор | | + | | декабрь |
| Интерактив такта | | + | | Дәрес саен |
| **Кадрлар шартлары** | | | | |
| Директор | | + | | |
| Милли белем бирү буенча директор урынбасары | | + | | |
| Укытучы | | + | | |
| **Мәгълүмати-шартлар** | | | | |
| Мәктәп сайты | | + | | Айга бер |
| Ата-аналар җыелышы | | + | | Декабрь. май |
| Массакүләм мәгълүмат чаралары | | + | | Чиреккә бер |
| **Мотивацион шартлар** | | | | |
| Семинар | + | | | апрель |
| Методик берләшмә утырышлары | | + | | Чиреккә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | бер |
| Педагогик киңәшмәләр | | + | | Август, май |
| **Оештыру шартлары** | | | | |
| Укучылар белән эшне оештыру | | + | | Ел буе |
| Ата-аналар белән эшне оештыру | | + | | Август, май |
| **Финанс шартлары** | | | | |
| Милли киемнәр | + | | | Ел буе |
| Методик чаралар | | + | | Ел буе |
| Методик- техник чаралар | + | | | Ел буе |

## 1.4. ПРОЕКТНЫҢ НӘТИҖӘСЕН, УКУЧЫЛАРНЫҢ РУХИ-ӘХЛАКЫЙ ТӘРБИЯСЕН БӘЯЛӘҮ ҺӘМ ТИКШЕРҮ МЕТОДИКАСЫ

Рухи-әхлакый сыйфатларны үстерүгә юнәлгән чараларның эффектлыгын түбәндәге методика аша бәяләп була. Ул берничә өлештән тора: Укучылардан сорау-җавап алу, аларны класстан тыш чараларда һәм эшчәнлек барышында күзәтү.

1. Анкета сораулары.

Анкета «Әхлакый төшенчәләр»

| | | |
|---|---|---|
| о Ихтыяр | о Тырышлык | о Кайгыртучанлык |
| о Яхшылык | о Намус | о Дуслык |
| о Кирелек | о Горурлык | о Бурыч |
| о Ялкаулык | о Җаваплылык | о Гаеп |

Һәр дөрес формалаштырган төшенчәгә 1 балл

2. Тестлар

3. Укучыларның үз-үзен тотышын тикшерү өчен ситуатив мәсьәләләр яки түбәндәге «Тәмамланмаган җөмләләр» биремен тәкъдим итәргә мөмкин

1. Әгәр мин берәрсенең мәгънәсез хәлдә калуын күрсәм, ...

2. Берәрсе минем уңышсызлыгымнан көлсә, мин....

3. Мине уенга алуларын теләсәм, мин ...

4. Әгәр миңа гел комачаулык тудырып торсалар, мин ....

5. Дәрестә дусларым белән уйныйсым килсә, мин ...

## 2. ТӨП ӨЛЕШ

## 2.1. ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК ПРОГРАММАСЫ

### 2.1.1.АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Туган як. Туган туфрак. Туган төбәк. Бу сүзләр өлкән яшьтәге кешеләр өчен генә түгел, һәр сабый бала өчен дә газиз һәм кадерле булырга тиеш.Туган якның табигате, аңа бәйле кызыклы фактлар, аның тарихы, халыкның көнкүреше, гореф – гадәтләре, милли йолалары балаларга белем һәм тәрбия бирүнең төп өлеше. Милли – төбәк компоненты, халык һәм милләт үзенчәлеген, алар мәдәниятен һәм рухи дөньясын, телен һәм тарихын, табигый – географик мохитен, хезмәтчел традицияләрен чагылдырган укыту материалын үз эченә берләштерә. Һәркем үзе яшәгән мөхиттә җиңел ориентлаша, аңа җайлаша белергә тиеш.

“Өч халык - өч мирас” дәрестән тыш эшчәнлек программасы төп белем бирү программасын нәтиҗәле үзләштерүгә юнәлгән. Максаты укучыларга милли төбәк компоненты аша рухи һәм әхлак тәрбиясе бирү һәм укучыларны социальләштерү. Дәрестән тыш эшчәнлектә укучы аңлап эшләргә, сизгер булырга, эзләнергә һәм кирәкле карарлар кабул итәргә өйрәнә, үзләре яшәгән җирдәге милли-төбәк компоненты белән якыннан танышачак, төрле милләтләрнең әдәби-мәдәни казанышларын, традицияләрен, милли асылын өйрәнәчәк.

“Өч халык - өч мирас” дәрестән тыш эшчәнлек программасы атнага бер сәгать исәбеннән 35 сәгатькә исәпләнгән.

**Сыйныф:** 7 нче (татар сыйныфы)

**Дәрестән тыш эшчәнлек формасы:** Төбәкне өйрәнү эше, фәнни-гамәли конференцияләр, олимпиадалар**,** ярышлар, эзләнү һәм фәнни тикшеренүләр, иҗтимагый-файдалы гамәлләр, экскурсия

**Дәрестән тыш эшчәнлек юнәлеше:** рухи-әхлакый

**Эшчәнлек төрләре:** әдәби-иҗади эшчәнлек, танып белү эшчәнлеге, уен эшчәнлеге, рухи кыйммәткә юнәлдерелгән проблемалы аралашу, төбәкне өйрәнү эшчәнлеге

**Дәрестән тыш эшчәнлек максатлары:**

Эшчәнлек буенча**:** эш гамәлләренә күнекмәләрне камилләштерү: ныгыту, эзләнү, текст, фотолар белән эш итү

Эчтәлек буенча: Авыл җирлегендә яшәүче халыкларның тормышы, көнкүреше, мәдәнияте турында белемнәрне ныгыту, формалаштыру.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Шәхескә кагылышлы:** җирлегебездә яшәүче халыкларны тану, аера белү, туган ягыбыз аның тарихына, мәдәниятенә карата патриотлык, горурлык хисе, бер-береңә карата ихтирам хисе тәрбияләү. дәрестән тыш эшчәнлектә өйрәнгән теманы, үзләштергән белемне гамәлдә куллана белү

**Метапредмет:**

эшчәнлекне планлаштыра белү, туган ягыбыз, җирлегебез турында булган белемнәрне киңәйтү, эзлекле һәм логик фикер йөртү, мөстәкыйль рәвештә карарлар кабул итә белү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү, проект эшчәнлеге тәҗрибәсен яклау.

**Танып белү УУГ:** кирәкле мәгълүматны таба белү; үз фикереңне дәлилли алу, мөстәкыйльлек булдыру, максат кую, текстны аңлап уку, сөйләм күнекмәләрен булдыру, эшне җаваплы аңлап башкару.

**Регулятив УУГ:** үз эшчәнлегеңне контрольгә алу,үзеңнең һәм башкаларның фикерен дөрес бәяләү, эшләнгән эшнең сыйфатын, дәрәҗәсен билгеләү.

**Коммуникатив УУГ:** сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү, коммуникатив максатлардан чыгып фикерне дөрес һәм урынлы куллану, төркемдә, парларда эшли белү, әңгәмәләрдә катнашу, мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару.

**Шәхси УУГ:** тыңлый һәм сораулар бирә белү, үз карашыңны дөрес әйтү һәм дәлилләү, иҗади хезмәттәшлеккә омтылу.

**Предметара бәйләнеш:** татар әдәбияты, татар теле, тарих, сәнгать.

**Эшне оештыру:** индивидуаль, парларда, төркемдә.

**Метод һәм алымнар:** эзләнү, укытучы сөйләве, укучыларның сорауга җавап бирүләре, текст белән эш, бәйләнешле сөйләм үстерү, дифференциаль якын килү һ.б.

**Җиһазлау:** ноутбук, интерактив такта, проектор, презентация, төсле кәгазь битләре, рәсемнәр, клей, кайчы

Дәрестән тыш эшчәнлекне **гомуми принциплары**

1. Гуманизация һәм гуманитаризация принцибы укучыларны кыйммәтләр системасында дөрес ориентлаша белергә һәм төрле мәдәниятләр диалогына керергә ярдәм итә.
2. Эчке һәм тышкы дифференциация принцибы — укучыларның иҗади эшчәнлекнең төрле юнәлешләрендә эшләү мөмкинлекләрен һәм сәләтләрен билгеләү һәм үстерү.
3. Сайлау иреге принцибы — укучыларның үзләренә дәрестән тыш эшчәнлекнең формаларын һәм төрләрен мөстәкыйль рәвештә сайлап алу мөмкинлеген тәкъдим итү, үзенең нәтиҗәләре өчен җаваплылык хисе тәрбияләү.
4. Ирекле үзбилгеләнү һәм үзреализацияләнү мөмкинлеге. Баланың шәхси мәнфәгатьләренә, ихтыяҗларына, сәләтенә йөз тоту.
5. Бердәмлек принцибы — укыту, тәрбия бирү, үсеш бердәмлеге.
6. Экологизация принцибы — балада әйләнә-тирә дөнья өчен җаваплылык хисе үстерү.

Дәрестән тыш эшчәнлек нәтиҗәләре. Уку елы ахырында укучыларның дәрестән тыш эшчәнлекнең тәрбияви нәтиҗәләре өч дәрәҗә буенча билгеләнә. Нәтиҗәләрнең беренче дәрәҗәсе — укучыларның социаль белем алуы, социаль чынбарлыкны һәм көндәлек тормышны аңлавы.

Нәтиҗәләрнең икенче дәрәҗәсе — укучы үзендә булдырылган социаль белемнәрен практик яктан раслый алуы, җәмгыятькә кагылышлы борчылуларын һәм позитив мөнәсәбәтләрен (кеше, гаилә, Ватан, табигать, дөнья, белем, хезмәт, мәдәният) белдерә алуы.

Нәтиҗәләрнең өченче дәрәҗәсе — укучының мөстәкыйль рәвештә башкарган гамәлләре. Бары тик мөстәкыйль рәвештә башкарган гамәлләр вакытында гына, ачык социумдагы эшчәнлегендә генә, мәктәпнең дустанә тирәлегеннән читтә булса гына яшь кеше, чынлыкта, социаль хезмәткәр, гражданин, ирекле кеше була ала. Дәрестән тыш эшчәнлек нәтиҗәләренең өч дәрәҗәсенә дә ирешү балаларда тәрбия һәм социальләшү эффектлары барлыкка килү мөмкинлеген арттыра.

## 2.1.2. ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК ПРОГРАММАСЫ ЭЧТӘЛЕГЕ

| № | Программа эчтәлеге | Оештыру формасы | Эшчәнлек төре |
|---|---|---|---|
| 1 | **Милли кием – 2 сәгать**<br>Рус, татар, керәшен халыклары костюмы - декоратив-гамәли сәнгать төре. Милли киемнәрнең тарихы. Костюм элементлары. | видеофильм карау<br>рәсем ясау | Танып-белү эшчәнлеге<br>Гамәли үзләштерү |
| 2 | **Милли орнамент – 2 сәгать**<br>Орнамент - милли костюмнарның структур элементы.<br>Рус, татар, керәшен халыклары орнаменты белән танышу. Мәктәп музеенда булу. | Төбәкне өйрәнү эше эзләнү | Танып-белү эшчәнлеге<br>Гамәли үзләштерү |
| 3 | **Милли кухня – 2 сәгать**<br>Рус, татар, керәшен халыклары кухнясы үзенчәлекләре. Гади ризык әзерләү рецептлары. | видеофильм карау<br>ризык әзерләү | Танып-белү эшчәнлеге<br>Гамәли үзләштерү |
| 4 | **Бию үзенчәлекләре – 3 сәгать**<br>Рус, татар, керәшен халыкларының бию үзенчәлекләре. Биюенең төрләре. Бию элементларын өйрәнү | видеофильм карау<br>бию хәрәкәтләре ясау | Танып-белү эшчәнлеге<br>Гамәли үзләштерү |
| 5 | **Йорт интерьеры – 2 сәгать**<br>Рус, татар, керәшен халыклары йорты интерьеры Йортын төзү үзенчәлекләре. Борынгы җиһазлар, аны әзерләү үзенчәлекләре<br>Мәктәп музеенда булу. | Төбәкне өйрәнү эше эзләнү | Иҗади эшчәнлек<br>Гамәли үзләштерү |
| 6 | **Милли традицияләр - 8 сәгать**<br>Рус, татар, керәшен халыкларының милли гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, йолалары, халык уеннары, милли кием үзенчәлекләре. Этнографик характердагы мәгълүматлар: характерлы милли исемнәр, халык бәйрәмнәре, халык уеннары - халык традицияләренә карата үз карашыңны белдерү. | Төбәкне өйрәнү эше уеннар | Танып-белү эшчәнлеге<br>Гамәли үзләштерү |
| 7 | **Халык иҗаты - 9 сәгать**<br>Фольклор, әкият, мәкаль, әйтем, бишек җырлары, мәзәк жанрлары белән танышу., чагыштырып өйрәнү. Халык иҗаты турында гомуми төшенчә. Халыкларның зирәклеге, акыл, зиһен үткенлеге. Табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәрнең сәнгать үзенчәлеге. Мәкальләрнең туры һәм күчмә мәгънәсе. | Төбәкне өйрәнү эше эзләнү | Иҗади эшчәнлек<br>Гамәли үзләштерү |
| 8 | **Проект эше – 3 сәгать .**<br>Проектларны әзеләү һәм яклау | Төбәкне өйрәнү эше эзләнү | Иҗади эшчәнлек<br>Гамәли үзләштерү |
| 9 | **“Театр – яктылыкка , нурга илтә!” - 4 сәгать**<br>Г.Камал, В.И. Качалов исемендәге Казан дәүләт академия, К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрларына бару. Спектакльләр карау аша рус, керәшен, татар халкының мәдәниятын өйрәнү. | Экскурсия, спектакль карау | әдәби-иҗади эшчәнлек<br>Гамәли үзләштерү |

### 2.1.3. КАЛЕНДАРЬ-ТЕМАТИК ПЛАН

| № | Тема | Чыганак | Планда гы дата | Фактта гы дата |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Кереш дәрес. Максатлар, бурычлар | https://imenkovo.ucoz.ru/index/chirpy_irle_zidar_se/0-127 | сентябрь | |
| 2. | Фольклор, экият, мәкаль жанрлары . | http://tatartelem.blogspot.com/p/blog-page_41.html | сентябрь | |
| 3. | Фольклор, экият, мәкаль жанрлары. | http://100tatarstan.ru/structure/profile/folklor-khalyk-khtere | сентябрь | |
| 4. | Әйтем, бишек жырлары, мәзәк жанрлары | http://www.teacher-rt.ru/index.php/biblioteka/d-biyat/981-khalyk_avyz_i_atynda_bishek_yrlary | сентябрь | |
| 5. | Әйтем, бишек жырлары, мәзәк жанрлары | https://dic.academic.ru/dic.nsf/ruwiki/2382 | октябрь | |
| 6. | Проект эше. Проект темаларын сайлау. | https://nsportal.ru/shkola/rodnoy-yazyk-i-literatura/library/2018/01/25/proekt-eshen-bashkaru-buencha-talplr | октябрь | |
| 7. | К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында “Назлы кияү” спектаклен карау | https://tinchurinteatr.ru/repertoire/ | октябрь | |
| 8. | Чырпы авылы жирлеге халыкларның зирәклеге, акыл, зиһен үткенлеге | https://tatarica.org/ru/razdely/municipalnye-obrazovaniya/municipalnye-rajony/laishevskij-rajon-1/chirpy | октябрь | |
| 9. | Табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәрнең сәнгать үзенчәлеге. | http://tatartelem.blogspot.com/p/blog-page_95.html | ноябрь | |
| 10. | Мәкальләрнең туры һәм күчмә мәгънәсе. | http://www.missiakryashen.ru/today/smi/stat/ | ноябрь | |
| 11. | Рус, татар, керәшен халыкларының милли гореф-гадәтләре | https://zen.yandex.ru/media/milliardtatar/10-faktov-o-kriashenah-osoboe-privetstvie-polovinka-monety-i-elabujskie-blondiny-60618c7f14931c44e867954f | ноябрь | |
| 12. | Рус, татар, керәшен халыкларының | https://nazaccent.ru/natio | декабрь | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | бәйрәмнәре, йолалары, халык уеннары. | ns/krjash/ | | |
| 13. | Рус, татар, керәшен халыкларының халык уеннары. | http://tuganaylar.ru/news/yashəy-rəveshe/kershen-etnik-trkemene-milli-traditsion-kalendar-byrmnre | декабрь | |
| 14. | В.И. Качалов исемендәге зур рус академия театрында Николай Коляда “Баба шанель” спектаклен карау | https://teatrkachalov.ru/ | декабрь | |
| 15. | Этнографик характердагы мәгълүматлар: милли исемнәр. | https://magarif-uku.ru/tt/tatar-isemnere/ | декабрь | |
| 16. | Этнографик характердагы мәгълүматлар: милли кушаматлар, фамилияләр. | https://nominic.ru/ | гыйнвар | |
| 17. | Этнографик характердагы мәгълүматлар: авыл исемнәре. | http://imenkowo.ucoz.ru/ | гыйнвар | |
| 18. | Этнографик характердагы мәгълүматлар: авыл тарихы. | https://tatarica.org/ru/razdely/municipalnye-obrazovaniya/municipalnye-rajony/laishevskij-rajon-1/meretyaki | февраль | |
| 19. | Рус, татар, керәшен халыклары костюмы - декоратив-гамәли сәнгать төре. | http://100tatarstan.ru/structure/profile/dekorativ-gamli-sngat-nrchelek-m-iat | февраль | |
| 20. | Милли киемнәрнең тарихы. Костюм элементлары. | https://tatarica.org/tat/razdely/narody/tatary/tradicionnaya-odezhda-i-obuv/milli-kiem | февраль | |
| 21. | Г.Камал исемендәге академия театрында К.Тинчуринның “Сүнгән йолдызлар” спектаклен карау | https://kamalteatr.ru/about-the-theatre/ | февраль | |
| 22. | Проект эшенең барышы. Фикерләр, этәргечләр | https://sch1354uz.mskobr.ru/files/trebovaniya_k_oformleniyu_7-11_klass.pdf | март | |
| 23. | Орнамент - милли костюмнарның структур элементы. | https://studopedia.ru/3_78751_ornament-v-kostyume.html | март | |
| 24. | Рус, татар, керәшен халыклары | https://lektsii.com/1-33320.html | март | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | орнаменты белән танышу. Мәктәп музеенда булу. | | | |
| 25. | Рус, татар, керәшен халыклары кухнясы үзенчәлекләре. Гади ризык әзерләү рецептлары. | https://tatarica.org/tat/razdely/narody/tatary/etnik-trkemnr/kershen-tatarlar | март | |
| 26. | Чырпы авылында ”Май чабу/Масленица” бәйрәмендә катнашу | https://www.livemaster.ru/topic/2743391-maslenitsa-istoriya-prazdnika-i-traditsii | март | |
| 27. | Рус, татар, керәшен халыклары кухнясы үзенчәлекләре. Гади ризык әзерләү рецептлары. | | апрель | |
| 28. | Рус, татар, керәшен халыкларының бию үзенчәлекләре. Биюенең төрләре. Бию элементларын өйрәнү | https://intertat.tatar/news/culture/23-04-2021/horeograf-d-l-t-umerov-tatar-biyuene-zamancha-metodikasy-yuk-5820454 | апрель | |
| 29. | Г.Камал исемендәге академия театрында Т.Миннуллинның “Гөргөри кияүләре” спектаклен карау | https://kamalteatr.ru/about-the-theatre/repertoire/ | апрель | |
| 30. | Рус, татар, керәшен халыкларының бию үзенчәлекләре. Биюенең төрләре. Бию элементларын өйрәнү | https://ru.wikipedia.org/wiki/Русский_народный_танец | апрель | |
| 31. | Мирәтәк авылында “Олы көн (пасха)” бәйрәмен күзәтү | http://tuganaylar.ru/news/җolalar-җaңarganda/olyi-kn-pasha-byrme | Апрель | |
| 32. | Рус, татар, керәшен халыкларының бию төрләре. Бию элементларын өйрәнү | | май | |
| 33. | Рус, татар, керәшен халыклары йорты интерьеры<br>Мәктәп музеенда булу. | Яндекс картинки | май | |
| 34. | Йортын төзү үзенчәлекләре. Борынгы җиһазлар, аны әзерләү үзенчәлекләре | Яндекс картинки | май | |
| 35. | Проектларны яклау. | | Май | |

## 2.2.“ӨЧ ХАЛЫК - ӨЧ МИРАС” ПРОЕКТЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУДА МӘКТӘП МУЗЕЕНЫҢ РОЛЕ.

Бүгенге көндә яшь буында туган якка мәхәббәт, патриотизм хисләре тәрбияләү, туган телеңне хөрмәт итү, туган халкың белән горурлану кебек ыйфатларны үстерү тәрбия өлкәсендә төп юнәлеш булып тора. Бу проблеманы чишү өчен, мәктәптә «Туган якны өйрәнү» музее эшли. Музей эшчәнлегендә катнашучы укучылар, туган як, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында белем туплап, уку-тәрбия мәсьәләләре белән генә шөгыльләнеп калмыйча, җәмгыятькә файдалы эш күнекмәләре дә ала. Алар кеше белән аралашырга, материал җыярга, җыелган материалны тиешле дәрәҗәдә туплап куярга да өйрәнәләр. “Өч халык - өч мирас”проекты кыссаларында музейда узачак дәресләр бигрәк тә нәтиҗәле булачак. Чөнки мәктәп музейларының үзләренә генә хас үзенчәлекләре бар. Беренчедән, алар укыту-тәрбия учагына әверелә, чөнки барлык җыелган материал укучыларның һәм укытучыларның үз куллары белән тәртипкә китерелгән һәм алар дәресләрдә бик кадерле, кызыклы күрсәтмәлелек ролен үти. Икенчедән, музей эшчәнлеге үзе үк укучылар үзидарәсенең эшчәнлегенә әверелә, аларны эзләнү-тикшеренү эшчәнлегенә тарта. Өченчедән, мәктәп музее ул – тарихи әйберләр туплау урыны гына түгел, ә фәнни-педагогик эшчәнлек алып бару урыны да. Җыелган материалны эшкәртү вакытында дәресләргә дидактик ярдәмлек тә эшләнә. Дүртенчедән, җыелган фондның күплеге һәм төп нөсхәлелеге мәктәп музейларын дәүләт музейлары белән тиңләштерә. Авыл тарихын, анда яшәүче халыкның көнкүрешен, төрле тармакта үсеш алган һөнәрчелек казанышларын, җирле топонимика, халык иҗатын, башка күренешләрне һәм, иң мөһиме, әлеге тарихны һәм сәнгатьне булдырган аерым кешеләр, шәхесләр язмышын, нәсел агачларын өйрәнү, алар белән бәйле документларны җыеп, саклап калу – мәктәп музее үз өстенә шундый бурычлар ала. Өлкәннәр тарафыннан авылның үткәне турында теркәп калдырылган язма чыганаклар, әлегә исән булган өлкән яшьтәгеләрнең истәлекләре, буыннан-буынга сөйләнеп килгән хатирәләр, вакыйгалар авылыбызның үткәнен бүгенгесе белән бәйли. «Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк», диләр. Киләчәкне булдыру өчен без туган нигез, туган авыл, ата-баба мирасы, шулай ук үз төбәкләренең казанышларын, күңел сыкраган, авырткан урыннарын белергә тиешбез, яхшы якка үзгәртү өчен туган җирне яратырга һәм горурланырга тиешбез.

“Өч халык - өч мирас” проектын гамәлгә ашыруда иң көтелгән һәм кирәкле нәтиҗәлрнең берсе – халыклар дуслыгы турында мавыктыргыч һәм кызыклы итеп сөйли белүче экскурсоводлар булачак.

## 3. ЙОМГАКЛАУ

Бүгенге көндә мәктәптә поликультуралы белем бирү юнәлешләрен камилләштерү өстендә җитди эш алып барыла.Укыту-тәрбия эшләрен оештыруда мәктәп җитәкчелеге, укытучылар эшчәнлегенең роле бик зур.

Поликультуралы белем бирү аша халыкларның бер-берсе белән мөнәсәбәтен көчәйтү һәм культурасын үзара баету, үз халкының тарихы һәм башка халыкларның яшәү рәвешен өйрәнү аша укучыда универсаль культура тәрбияләү - заманча белем бирүнең мөһим өлеше булып тора. Бер генә милләт тә үз мәдәнияте кысаларында гына бикләнеп кала алмый. Шуңа күрә бүгенге көндә поликультуралы җәмгыятьтә яши алучы функцианаль белемле укучылар тәрбияләү милли мәгариф системасының яңа стандартларында да төп урында тора. Милли мәктәпләрдә белем алучы укучылар татар һәм рус мәдәнияте белән генә чикләнмәскә, әйләнә-тирәбездә яшәүче башка милләтләрнең мәдәнияте белән дә таныш булырга тиешләр. Балаларны балачактан күп милләтле мохиттә яшәргә, яшәеш өчен кирәкле белем алырга өйрәтсәк, киләчәктә аның камил шәхес булуы ышанычлы. Шуңа күрә дә мин үземә “Уку процессында укучыларны төрле милләтләрнең культураларына якынайту, аралаша белү һәм төрле милләтле дәүләттә яшәргә өйрәтү” дигән максатны куйдым.

Безне алга чыгарачак яңа буын бүген мәктәптә формалаша. Хәзерге дөньяда шәхесне формалаштыручы төп фактор буларак, белем һәм тәрбия бирүнең әһәмияте арта бара. Бүгенге балаларда әхлакый нигезләр, тирә - яктагыларга карата ихтирам һәм толерант мөнәсәбәт, патриотлык, гражданлык хисе һәи узара тату яшәү культурасы тәрбияләү мөһим- дип белдерде үзенең бер чыгышында Татарстанның беренче президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев. В.В. Путин да бу мәсьәләнең мөһимлегенә басым ясады “Без Рәсәй Федерациясендә яшәүче һәрбер милләткә зур хөрмәт белән карыйбыз, карарга тиешбез һәм караячакбыз да. Безнең матурлыгыбыз һәм көчебез - күпмилләтлелегебездә”

Әйе, җәмгыятебезнең киләчәге бүген мәктәптә укучы егет һәм кызларның гражданлык сыйфатларына, чын патриотлар булып үсүенә бәйле. Үз иле, үз халкы белән горурланган кеше генә башка халыкның телен, мәдәниятен, әдәбиятын хөрмәт итә.

Татар мәктәбенең максаты - милләт өчен киләчәк әзерләү.

## 4. КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ


1. “Мәгариф турында” Россия Федерациясе Законы
2. “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законы (6, 7, 10, 32 нче маддәләр)
3. Нәбиуллина Г.Ә., Гыйләҗева Л.Г.,Дөньяда сүзем калыр.-Казан:Татар.кит.нәшр.,2012.-495б.
4. Россия Федерациясе мәгариф һәм фән министрлыгының 1897 нче боерыгы белән расланган төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандарты.
5. Мәшһүр мәгрифәтъче-галим, педагог Ризаэддин Фәхреддин мирасын укыту-тәрбия процессында файдалану. Школа. Казан. 2009
6. Тәрбия теориясе һәм методикасы. Казан. “Мәгариф”нәшрияты, 2006
7. Хуҗиәхмәтов Ә. “Әхлак тәрбиясе”. Мәгариф, №1,2005.
8. Хуҗиәхмәтов Ә. “Тәрбия- мәңгелек фәлсәфә”. Мәгариф нәшрияты,
9. Шәмсетдинов Г. ”Әхлак тәрбиядән башлана”. Мәгариф-№4, 2005